
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



# С 23 февраля!

№6
Февраль, 2025 г.




Дорогие ученики и учителя, с 23 Февраля! Будьте всегда настоящими мужчинами, какие бы трудности и неожиданные повороты не встречались. Пусть вами гордятся, любят и ценят, а вы никогда не обидите и не предадите. Пускай жизнь не преподаёт вам слишком жестких уроков, старайтесь учиться на чужих ошибках и поступать только мудро, взвешенно и правильно. Будьте всегда справедливы и уверенны в себе. Желаем вам стать настоящими защитниками, крепкими бойцами и борцами за своё счастье, за достойный успех. Здоровья вам, бодрых сил и верной дружбы в жизни.

Хөрмәтле укучылар һәм укытучылар, 23 февраль белән сезне! Тормышта нинди генә кыенлыклар һәм көтелмәгән борылышлар килеп чыкса да, һәрвакыт чын ир-ат булып калыгыз. Сезнең белән һәр жирдә һәм һәрвакыт горурлансыннар, үзегезне яратсыннар, хезмәтегезне бәяләсеннәр. Сез—безнең ныклы таянычыбыз. Һәрвакыт гадел һәм үзүзегезгә ышанычлы булыгыз. Тормыш сезгә артык катгый таләпләр куймасын. Сезнең якыннарыгызны яклаучы, көчле ихтыярлы көрәшче буларак хөрмәт итсеннәр. Сезгә сәламәтлек, жан тынычлыгы, гаилә бәхете һәм тормышта тугры дусларыгыз янәшәгездә булуын телибез. Илебез күге һәрчак аяз, дөньябыз һәрчак тыныч булсын.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре | 2 |
| Әфган сугышы эзләре | 3 |
| Сабантуй — бөтенхалык бәйрәме | 4 |
| Из школьной жизни... | 5 |
| Страница юного поэта | 6 |
| Тәмле тамак | 6 |

# Муса Җәлил һәм аның көрештәшләре

Бөек Ватан сугышының халкыбызга зур сынаулар, куркыныч фаҗигаләр алып килгәнлеге һәммәбезгә мәгълүм. Нинди генә аяныч һәлакәтләр килеп туган чорларда да авырлыклар алдында баш имәгән, рух ныклыгын югалтмаган халкым. Шартлары авыр булса да, фронттагы, хәтта фашист концлагерьларындагы тормыш, барыбер дәвам иткән, үлем-хәсрәт тә, кайгы-яшь тә кешеләрнең яшәүгә омтылышын туктата алмаган.

Фашист Германиясе башлаган сугыш китергән күпсанлы фаҗигале бәлаләрнең берсе — әсирлек булган. Без Ватандашларыбызның якты истәлегенә олы хөрмәт белән карарга тиешбез. Әле һаман да билгесезлектә кала биргән меңләгән татар легионерларының исемнәрен барлау, киләчәк буынга житкерү буенча эзләнүләр дәвам итә. Гомумкешелек кыйммәтенә аңлы караш тәрбияләү бүгенге көндә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Илебез азатлыгы өчен гомерләрен биргән, әле дә исемнәре киң җәмәгатьчелеккә җиткерелмәгән ватандашларыбызны барлау; озак еллар дәвамында хаксызга рәнҗетелгән, "оныттырылган" чын каһарманнарыбызның данлы исемен яшь буынга таныту мөһим. Халкыбызның батыр уллары турында өйрәнеп, бүгенге һәм киләчәк көн укучысына җиткерү безнең бурыч булып тора. Әгәр без шулар үрнәгендә тәрбияләнсәк, буыннар бәйләнеше беркайчан өзелмәс.

Сугыш турында мин күп китаплар укыдым, чөнки үземнең явыз фашист пулясыннан һәлак булган бабам, туганнарым язмышы турында күбрәк беләсем килде. Заманында, сугышның авыр шартларында чарасыздан фашистлар кулына төшүгә карамастан, һич тә гаебе булмаган әсирнең гаепле саналуы, аңа берәүнең дә ышаныч белән карамаганлыгы җанымны өшеткәндәй булды. Хәтта аның гаиләсенә күләгә төшергәннәре, эти-әниләре, туганнары кимсетелү кичергәннәре хакында укыгач, бөтенләй тетрәнеп калдым.

1942 елның көзендә, немец гаскәрләренең Сталинградка һөҗүме башлангач, басып алынган Польша территориясендә, Радомнан ерак булмаган Едлино янында «Идел-татар» («Идел- Урал») легионын оештыруга хәзерлек эшләре башланган. Татар әсирләрен беренче җыю урыны Едлинога якын гына булган Сельдце «А» дигән җирдә булган. Июль аена анда инде 2550 әсир тупланган. Икенче җыю урыны Демблиндәге 307 нче «шталаг»та (лагерь) 1942 елның 1 сентябренә 1800 татар әсирен туплаганнар. Германия командованиесе татар легионерларын өйрәтүне һәм «тәрбияләүне» 1942 елның 1 октябреннән 1943 елның 1 гыйнварына кадәр үткәрергә планлаштырган.

Легион белән житәкчелек итү 1875 елда Мәскәүдә туып-үскән, русча иркен сөйләшүче майор Оскар Зеккендорфка йөкләнгән. 70 не куып килүче бу карт, легион белән житәкчелек иткән чакта, подполковник дәрәжәсенә күтәрелгән. Татар легионерларыннан аерым батальоннар төзеп сугышка жибәрү планлаштырылган.

«Идел-Урал» легионына килеп эләккән әсир ватандашларыбызның Гайнан Кормаш - Муса Җәлил (Гумеров) группасында нацизмга каршы яшерен көрәш җәелдерү турында Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Шәйхи Маннур һәм башка каләм ияләренең хезмәтләрендә шактый күп мәгълүматлар бар.

Легионерлар арасында Татарстанның Сарман районы Яхшыбай авылында туып-үскән Гокәшә Хәйруллин, Раян Зәбиров, Азнакай районының Октябрь Бүләге авылыннан Гомәр Асибаков та була. Заманында генерал де Голль бүләгенә ия булган алар.

Зинданнарга ташланган Җәлил һәм яшерен оешма әгъзаларының күргән-кичергәннәрен бернинди бизмән белән дә үлчәп бетерерлек түгелдер, минемчә. Әле бит әсирлектә язган шигырьләре илгә кайтмаган булса, каһарман Җәлилгә дә сатлык җан мөһере сугылган булыр иде. Дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре»н саклап калуда чын егетлек күрсәткән Г. Шәрипов, Н. Терегулов, француз патриоткасы М. Дебиезе, Бельгия гражданы А.Тиммерманска («Моабит дәфтәрләре»нең икенчесен саклап калганы өчен, совет хөкүмәте 1966 елда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгән) рәхмәт.

Каһарманнарның һәркайсына — хәтта кайберләре инде исән булмаса да — Россия, Татарстан хөкүмәтләре тарафыннан тиешенчә бәһа бирелергә тиештер.

Ә без – яшь буын - фашистлар җирлегендә һәлак булганнар алдында мәңгегә бурычлы. Безнең ул каһарманнарны, шәһитләребезне хәтердән чыгарырга һич кенә дә хакыбыз юк!..

*Камилә Мифтахова, 11 нче сыйныф укучысы.*

# Әфган сугышы эзләре

Рәсми хәбәрләргә караганда, Әфганстаннан 15 меңгә якын солдат үз туган җирләренә әйләнеп кайтмаган. Хәбәрсез югалганнар исемлегендә әлегә кадәр 273 кеше исәпләнә. 53 меңнән артык солдат контузия ала һәм яралана.

Әфган сугышы безнең Арча районын да читләтеп үтмәгән. Сугышка чакырылган егетләребезнең өчесе туган нигезләренә әйләнеп кайтмаган. Менә алар: Пөшәнгәр егете Әһлиуллин Васил Габдулла улы, Поч-Поник авылыннан Бикбаев Фәнис Мөхәммәт улы, Арчадан Лотфуллин Марат Әлтаф улы. Мәктәбебезне тәмамлаган каһарманыбыз хакында 19 еллык тормыш юлын яктырткан «Әфган сугышы хатирәләре китабы» бастырылып чыкканга да дүрт ел үткән.

Гаиләләре белән Красноярск өлкәсе Норильск шәһәреннән Арча эшчеләр төбәгенә 1978 нче елның апрелендә күченеп кайта алар. Маратны, укырга 2 нче мәктәпкә бирәләр. Ул классташлары белән бик тиз дуслашып китә. Аларны гел көлдереп, төрле мавыктыргыч һәм кызыклы хәлләр сөйләргә ярата. Дәресләрдә зирәк һәм тапкыр җаваплары белән барысын да таң калдыра.

Югары сыйныфта укыганда комсомол комитеты әгъзасының портреты Мактау тактасында эленеп тора. Укытучылары, аның өлкәннәргә, иптәшләренә карата бик игътибарлы булуын искә алалар. Үз сүзендә тора белгәнлектән, аңа сыйныфташлары арасында хөрмәт зур була. Төрле спорт секцияләре һәм бокс белән дә шөгыльләнә.

Казан төзүче-инженерлар институтының юллар төзү бүлегендә укыган вакытта, 1986 елның маенда, армиягә алыну турында хәбәр килү сәбәпле, Маратка һәм аның төркемендәге егетләргә имтиханнарны иртәрәк бирергә мөмкинлек тудыралар. Шушы елның маенда Маратны армия хезмәтенә җибәрәләр.

Июнь аеннан декабрьгә кадәр Марат Таджикстанның Теджен шәһәрендә хәрби өйрәнүләр үтә. Аннары аны Әфганстандагы танк батальонының 191 нче укчылар бригадасына юллыйлар. Армиядән Марат берничә хат язарга өлгерә. Язган һәрбер хатында аның тормышны, кешеләрне яратуы сизелә. Барыннан да бигрәк ул әти-әнисен ярата. Өенә ул бик җылы хатлар юллый: “Кайгырма, борчылма, елама әни. Көт, мин кайтырмын...” Барлык хатлар да: “Тиздән очрашканга кадәр” дип тәмамлана.

Ә бу куркыныч очрашу, егетнең үле гәүдәсен цинк табутта алып кайтканда, 1987 елның апрелендә була... 1987 елның 8 апрелендә танк ротасы алда торган хәрби хәрәкәтләр буласы районга маршрут ясый. Пушкага снаряд куеп торучы Лотфуллин танк колоннасының “башы”нда була. Танкка каршы куелган мина шартлап, чылбырны өзә. Төзекләндерергә дип экипаж читкә чыга. Чылбырны рәтләгәнче, Марат автоматтан атып иптәшләрен саклый. Шушы атуда ул яраланып үлемгә дучар була.

Батыр якташыбыз Лотфуллин Марат Әлтаф улы, үлгәннән соң, Кызыл Йолдыз Ордены белән бүләкләнә.

***Гүзәлия** Фәттахова, 11 нче сыйныф укучысы.*



# Сабантуй — бөтенхалык бәйрәме

Безнең әби-бабайларыбыз заманында Сабантуй бәйрәме зур вакыйга булып исәпләнгән һәм аны бәйрәм итүгә хәзерлек эшләре озак барган. Кыш буена хатын-кызларыбыз бәйрәмгә бүләк әзерләгән, теккән, чиккән. Яз җитү белән малайлар йомырка, ә егетләр сөлге җыйган. Милли бизәкләр белән чигелгән сөлге иң кадерле бүләк булып саналган. Сөлге җыю, гадәттә, җыр-бию, уен-көлке белән бергә алып барылган. Бүләкләр колга башына эленгән, ә кайчак- та егетләр үзләрен урап бәйләп куя торган була. Йомыркаларның җыюы да гадәттәге була. Аларны бирәләр бүләк урынына да, һәм бүләк белән бергә дә бирәләр. Йомыркаларны чиләккә җыялар. Алардан өлешне саталар, ә җыел- ган акча Сабан туйга кирәкле әйберләр алу өчен бара. Үзенә күрә Сабантуй шурасы булып саналган аксакаллар, ярышлар вакытында тәртип саклаган һәм җиңүчеләрне бүләкләү өчен жюри әгъзаларын билгеләгән. Бәйрәмнең кульминациясе - мәйдан. Элегрәк ярышлар тәмамлангач, кичкә таба Сабантуй мәйданына яшьләр «кичке уен»га җыелган.

Татарстан Республикасында Сабантуй бәйрәме июнь аенда, гадәттә 3 этапта үткәрелә. Бәйрәмнең аерым билгеләнгән датасы юк. Язгы кыр эшләре тәмамлануны башта авыл халкы бәйрәм итә, аннан Сабантуй республикабызның зур шәһәрләрендә гөрләп уза. Соңгы этап башкалабыз Казанда үткәрелә. Зур-зур мәйданнарда спортчылар, сәнгать осталары ярыша. Үзәк ипподромда ат чабышлары үткәрелә. Халык куңел ача. Монда чит илдән килгән кунаклар да бик теләп катнаша. Бәйрәм көне буе дәвам итә.

Хәзерге көндә татар бәйрәме Сабантуй милли кысаларда гына туктап калмый, киң, бөтенхалык бәйрәменә әверелеп бара. Аны хәзер хезмәт һәм шатлык бәйрәме дип кенә түгел, ә халыклар дуслыгы бәйрәме дип тә атыйлар, чөнки, бу бәйрәмдә, күпмилләтле Россиянең бар милләт вәкилләре дә бик теләп катнашалар.

Сабантуйга берничә көн кала, элек-электән килгән матур йола – бирнә-бүләк җыю йоласы башкарыла. Күп җирдә ул сөрән салу буларак билгеле. Бу йоланы «яулык бәйрәме», «сөлге җыю, «сөрән салу», «бирнә җыю», «ат аягын кыздыру», «яулык җыю» дип атаучы авыллар да бар. Кайда бизәлгән атлар җигеп, кайда җәяүләп сөрән салалар. Җиңел машина да эшкә җигелә хәзер. Әмма һәркайда гармун тартып, милли киемнәрдән, җырлап-биеп, күтәренке рухта үткәрергә тырышалар бу йоланы.

Бүләкләр кичке якта, кешеләр эштән кайткач, яисә ял көнендә җыела. Көне алдан хәбәр ителә, йола үтәүгә хатын-кызлар, балалар да кушыла. Кайбер авылларда нәниләрне конфет чәчеп сөендерәләр. Капка төбендә табын әзерләп көтеп торучылар да очрый. Һәркем бәйрәмгә үз өлешен кертеп калырга тырыша. Ел саен бүләкләрен алдан әзерләп көтеп торалар. «Сабан туенда иң соңлап килгән атка», «иң яшь көрәшчегә», «авыш баганага менүчегә», беренче килгән йөгерешчегә» дип, бүләкне атап бирүчеләр дә бар. Күп кеше тәмле телен, җыр-биюен, җор сүзен эшкә җигеп каршы ала сөрәнчеләрне. Кызлар, егетләр һәр капка төбендә биеп, җырлап үтәләр. Бүләккә дип тапшырылган сөлгеләр, тукымаларны ат арбасындагы колгага элэләр. Бүләк җыю үзе бер бәйрәмгә әверелә. Кайбер авылларда әле Сабан туена йомырка җыю йоласы да сакланып калган. Бүләк җыйганда, бүләк тапшырган кешене чөю гадәте дә бар. Кайбер авылларда яшь киленнең бүләк бирү йоласы да сакланган. Ул элеккеге кебек чиккән сөлге түгел инде. Яшь килен, гадәттә, бүләк итеп берәр күлмәк алып куя, ул күп вакыт ир-егет күлмәге була.

***Әмир** Гыйлфанов, 9А нчы сыйныф укучысы.*






# Из школьной жизни...

6 февраля прошел школьный танцевальный конкурс «Танцы. Школа» среди 5-11 классов. Танцевальные композиции - народные и современные, задорные и лирические, красочные и заводные показали большой творческий потенциал учеников.

Результаты конкурса:
«Самый зажигательный танец»: 6А класс;
«Самый романтический танец»: 9А класс;
3 место: 5В, 6Б, 7А класс;
2 место: 6В, 7Б, 7В, 11 класс;
1 место: 8А, 8Б, 8В, 10 класс;
ГРАН-ПРИ: 5А, 9Б класс.

Праздник танца оставил у зрителей массу необыкновенных и удивительных впечатлений. Конкурс показал, что появляются новые таланты, интересные и содержательные номера. В этом и есть прелесть ожидания участия в следующем мероприятии.






Завершился школьный танцевальный конкурс «Танцы. Школа». 7 февраля в нём приняли участие обучающиеся 1-4 классов. Классные руководители переживали за своих учеников больше, чем они сами. Одноклассники и друзья поддерживали артистов бурными аплодисментами. Конкурс оставил у ребят и жюри самые яркие впечатления, положительные эмоции и заряд энергии для новых свершений!

Итоги конкурса:
3 место: 1Б, 2В, 3Б, 4Б.
2 место: 2Б, 4А.
1 место: 2А, 4В.
ГРАН-ПРИ: 1А, 3А.



13 февраля прошел районный конкурс театральных постановок на военно- патриотическую тематику «Защитникам Родины посвящается...», приуроченного Дню защитника Отечества.

Такие театральные смотры выявляют творчески одаренных детей, создают условия для появления новых и укрепления уже существующих коллективов.

Нашу школу достойно представил школьный театр «Сәхнә». Они заняли 2 место!

Руководители: Забирова Э.Ш., Хабирова Р.Б.





# Страница юного поэта...

**Страна моя родная.**

В сиянье утренней зари
Встаёт держава величаво.
И льются песни до зари,
И множит время нашу славу.

Здесь в каждом городе своём
Живут легенды и преданья.
Мы эту землю бережём,
Храним священные познанья.

От моря синего до гор,
От тундры до степей бескрайних
Раскинул крылья твой простор,
Земля чудес необычайных.

В тебе и сила, и покой,
И мудрость древняя народа.
Звенит под солнцем золотой
Напев свободы и природы.

Цвети, любимая земля,
Расти детей своих достойных.
Пусть будут мирными поля,
И песни льются в душах вольных.

**Вам Россию не понять.**

Умом Россию не измерить,
В неё возможно только верить,
Сквозь время открывая дверь и
Познав особенную твердь.

В ней всё особое таится,
В ней время по-другому длится,
И может заново родиться
Душа, как вольная жар-птица.

Здесь мысли чище и светлей,
И песни звонче и сильней,
И нет просторов тех милей,
Где даль сливается с землёй.

В ней всё и просто и непросто,
От малой травки до погоста,
От детской песенки до роста
Души в космическую россыпь.

Здесь каждый шаг - как откровенье,
Здесь каждый миг - как вдохновенье,
И нет конца и нет сомненья,
Что врагам нас не понять.

***Эльвира** Насифуллина, 7А класс.*

# Тәмле тамак

**Камыр кую**

Беренче яки югары сортлы оннан ачы камыр изәләр. Моның өчен җылы суга сөт өстәп, чүпрә, шикәр комы салалар һәм яхшылап болгаталар, йомырка, эретелгән маргарин, тоз салып тагын болгаталар. Башта камыр каймак куелыгында булырга тиеш, аннары аңа иләнгән он өстәп, камырны куерта төшәргә кирәк. Аны, өстән каплап, җылы урында ачыталар. Бер күпереп менгәч, өстен ачып, баскалап куярга кирәк, бер-ике тапкыр шулай эшләргә мөмкин. 1,5-2 сәгатьтән камыр кирәгенчә ачый.

1 кг камыр өчен: 600-650 г он, 20-25 г чүпрә, 30 г шикәр комы, 1-1,5 йомырка, 50-60 г маргарин, 100-120 г сөт, 150-200 г су, 10-20 г тоз. Әлеге камырдан бәлеш, өчпочмак, пәрәмәч кебек итле ризыклар тәмле була.

***Мәликә** Җәләева, 9А классы*

***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Гузелия Фаттахова
***Фотокорреспондент*** Илюза Шамсемухаметова
***Корректор*** Гузелия Фаттахова
***Редколлегия*** Камилла Мифтахова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2